| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**___16.12.2019___** г. Казань №**____2505_____**

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында
булган дәүләт казна учреждениеләре булып торучы
медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган
медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны)
билгеләү тәртибен раслау турында

2012 елның 4 октябреннән № 1006 Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Медицина оешмалары тарафыннан түләүле медицина хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләренең 8 пунктына туры китереп, боерам:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында булган дәүләт казна учреждениеләре булып торучы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны) билгеләү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары А.Д. Гариповка йөкләргә.

Министр М.Н. Садыйков

16.12.2019 № 2505
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган

# Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында булган дәүләт казна учреждениеләре булып торучы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны) билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында булган дәүләт казна учреждениеләре (алга таба – учреждениеләр) белән күрсәтелә торган медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны) билгеләү максатларында эшләп чыгарылган.

2. Учреждениеләр 2017 елның 13 октябреннән №804н «Медицина хезмәтләре номенклатурасын раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы белән расланган медицина хезмәтләренең номенклатурасын исәпкә алып, түләүле медицина хезмәтләре исемлеген формалаштыралар.

3. Учреждениеләр эшчәнлекнең төп төрләре буенча учреждение тарафыннан медицина хезмәтләрен күрсәтүгә исәпләү һәм исәпләү-норматив чыгымнар күләме, шулай ук учреждение мөлкәтен карап тотуга исәпләү һәм исәпләү-норматив чыгымнар күләме нигезендә медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны) мөстәкыйль рәвештә билгелиләр, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

узган чорларда эшчәнлекнең төп төрләре буенча медицина хезмәтләре күрсәтүгә учреждениенең фактик чыгымнарының анализын;

табигый монополияләр субъектлары товарларына, эшләренә, хезмәт күрсәтүләренә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) кертеп, эшчәнлекнең төп төрләре буенча учреждение тарафыннан медицина хезмәтләрен күрсәтү чыгымнары составында бәяләр (тарифлар) дәрәҗәсенең үзгәрү динамикасы турында фаразлау мәгълүматын;

охшаш хезмәтләргә базар тәкъдимнәренең хәзерге һәм фаразлана торган күләменең һәм аларга бәяләр (тарифлар) дәрәҗәсенең анализын;

охшаш хезмәтләргә ихтыяҗның хәзерге һәм фаразлана торган күләменең анализын.

4. Медицина хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) әлеге хезмәтләр күрсәтүгә учреждениеләрнең чыгымнарын каплауны исәпкә алып билгеләнәләр, шул ук вакытта рентабельлекнең 20 проценттан да артмавын күздә тоту киңәш ителә.

5. Төнлә, шулай ук ял һәм бәйрәм көннәрендә түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү өчен учреждениеләр әлеге хезмәтләргә расланган бәяләргә (тарифларга) арттыру коэффициентын кулланырга хокуклы, ләкин түбәндәгеләрдән арттырмыйча:

төнлә түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү өчен – 30%;

ял һәм бәйрәм көннәрендә түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү өчен – 50%.

6. 2012 елның 4 октябреннән № 1006 Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары белән расланган Медицина оешмалары тарафыннан түләүле медицина хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләренең 7 пунктында каралган, учреждение тарафыннан күрсәтелә торган түләүле медицина хезмәтләре исемлеге, медицина хезмәтләренә бәяләр (тарифлар), шулай ук түләүле медицина хезмәтләре исемлегенә үзгәрешләр һәм медицина хезмәтләренә бәяләрнең (тарифларның) үзгәрешләре учреждение боерыгы белән расланалар.

7. Түләүле медицина хезмәтләре исемлеген һәм медицина хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны) раслау турында яисә әлеге боерыкка үзгәрешләр кертү турында учреждение боерыгының күчермәсе аның бастырылып чыгарылган көненнән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелә.